# РӘСӘЙ ФЕДЕРАЦИЯСЕ

# ФЕДЕРАЛЬ КАНУН

## ГРАЖДАННАРНЫҢ АЕРЫМ КАТЕГОРИЯЛӘРЕН СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ ГАРАНТИЯЛӘРЕ ТУРЫНДА

2015 елның 22 маенда

Дәүләт Думасы тарафыннан

кабул ителгән

2015 елның 3 июнендә

Федерация Советында

хупланган

**Маддә 1. Әлеге Федераль канунның җайга салу предметы**

Әлеге Федераль канун Кырым Республикасын Рәсәй Федерациясенә кабул итү һәм Рәсәй Федерациясе составында яңа субъектлар - Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре – барлыкка килү белән бәйле рәвештә Рәсәй Федерациясе гражданнарының аерым категорияләрен социаль яклау гарантияләрен билгеләүне күздә тота.

**Маддә 2. Әлеге Федераль канунны куллану**

Әлеге Федераль канун Рәсәй Федерациясе гражданнарының түбәндәге категорияләренә кагыла:

1) 2014 елның 18 мартына кадәр Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә даими яшәүче һәм 2014 елның 18 мартына кадәр Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территориясендә 2014 елның 21 февраленә кадәр гамәлдә

булган кануннар нигезендә билгеләнгән ай саен бирелә торган гомерлек акчалата асрау алучы отставкадагы судьяларга;

2) 2014 елның 18 мартына кадәр Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә даими яшәүче һәм 2014 елның 18 мартына кадәр Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территориясендә 2014 елның 21 февраленә кадәр гамәлдә булган кануннар нигезендә ай саен бирелә торган гомерлек акчалата асрау хокукына ия булган отставкадагы судьяларга;

3) 2014 елның 18 мартына Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә даими яшәүче һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территориясендә эшләүче судларның судьялары вазифаларын үтәгән һәм 2014 елның 23 июнендәге 156-ФЗ номерлы «Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә барлыкка килгән федераль судларның беренче составларына кандидатларны сайлап алу тәртибе турында» Федераль канун нигезендә Рәсәй Федерациясе судларының беренче составларын формалаштырганда билгеләнмәгән судьяларга;

4) 2014 елның 18 мартына Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә даими яшәүче һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территориясендә эшләүче судларның судьялары вазифаларын үтәгән һәм 2014 елның 23 июнендәге 156-ФЗ номерлы «Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә барлыкка килгән федераль судларның беренче составларына кандидатларны сайлап алу тәртибе турында» Федераль канун нигезендә Рәсәй Федерациясе судларының беренче составларын формалаштырганда билгеләнгән судьяларга;

**Маддә 3. Тиешле еллар эшләгән өчен ай саен бирелә торган өстәмә билгеләү, тиешле еллар эшләгәнгә исәпләү тәртибе, ай саен бирелә торган гомерлек тоту һәм ял пособиесын билгеләгәндә эш стажын исәпләп чыгару**

1. Әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсенең 2-нче пунктында күрсәтелгән Рәсәй Федерациясе гражданнарына ай саен бирелә торган гомерлек акчалата асрауны билгеләү өчен эш стажына түбәндәге эш чорлары кертелә:

1) ССҖ Берлеге, Украина судларының судьялар вазифаларын башкару чоры;

2) Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә 2014 елның 21 февраленә кадәр гамәлдә булган кануннар нигезендә судьяларның тиешле еллар исәбенә кертелгән башка вазыйфаларны башкару чоры.

2. Әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсенең 3-нче һәм 4-нче пунктларында күрсәтелгән Рәсәй Федерациясе гражданнарына тиешле еллар эшләгән судьяларга ай саен өстәмә түләү билгеләү өчен тиешле елларын эшләүгә түбәндәге эш чорлары кертелә:

1) ССҖ Берлеге, Украина судлары судьялары вазыйфаларын башкаргу чоры;

2) Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә 2014 елның 26 декабренә кадәр эшләгән суд судьялары вазыйфаларын башкару чоры;

3) Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә 2014 елның 21 февраленә кадәр гамәлдә булган кануннар нигезендә судьяларның тиешле елларын эшләгән башка вазыйфаларын башкару чоры.

3) Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә 2014 елның 21 февраленә кадәр гамәлдә булган кануннар нигезендә судьяларның тиешле елларын эшләгән башка вазыйфаларын башкару чоры.

3. Әлеге Федераль законның 2-нче маддәсендәге 3-нче һәм 4-нче пунктларында күрсәтелгән Рәсәй Федерациясе гражданнарына эш стажына айлык гомерлек асрау һәм ял пособиесын исәпләү өчен ССҖ Берлегендә, Украина судларында, Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә 2014 елның 26 декабренә кадәр гамәлдә булган кануннар нигезендә, һәм шулай ук алдагы вазыйфалары 1996 елның 10 гыйнварындагы 6-ФЗ номерлы Федераль канунның 7-нче маддәсе "Рәсәй Федерациясе судлар аппаратында эшләүче һәм судьяларның өстәмә социаль яклау гарантиясе" ндә күрсәтелгән эш вакыты, төрле катлау һәм юрисдикциясендә суд судъясы булып тиешле еллар эшләгән судьяларга эш вакыты исәпләнә.

**Маддә 4. Гомерлек асрау һәм ял пособиесен билгеләү, түләү тәртибе**

1. Әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсендәге 2-нче һәм 3-нче пунктларында күрсәтелгән затлар үз теләге буенча гомуми нигезләрдә пенсия билгеләү яисә 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы "Рәсәй Федерациясендә судьялар статусы турында" Рәсәй Федерациясе Канунының 15-нче маддәсендәге 5-нче пункты нормалары нигезендә ай саен гомерлек асрау хокукына ия.

2. Әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсендәге 1-нче пунктында күрсәтелгән затларга Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә 2014 елның 21 февраленә кадәр гамәлдә булган кануннар нигезендә билгеләнгән ай саен гомерлек асрау күләме түләнә. Шул ук вакытта айлык гомерлек акчалата асрауның гомуми күләме айлык акчалата асрау күләменнән, шулай ук әлеге Федераль канун үз көченә кергән көнгә акчалата формада билгеләнгән һәм бу затларга түләнә торган башка гарантияләрдән түбән була алмый.

3. Әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсендәге 3-нче пунктында күрсәтелгән затларга:

1) ял пособиесе 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы "Рәсәй Федерациясендә судьялар статусы турында" Рәсәй Федерациясе Канунының 15-нче маддәсендәге 3-нче пункты нормалары нигезендә түләнә";

2) гомерлек асрау һәм ял пособиесы тиешле судья вазыйфасында эшләүче затка айлык эш хаку күләменнән чыгып исәпләнә. Шул ук вакытта әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсендәге 3-нче пунктында күрсәтелгән затларның вазыйфалары әлеге Федераль канунга кушымта нигезендә Рәсәй Федерациясе судлары судьяларының тиешле вазыйфаларына туры килә дип санала.

4. Әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсендәге 1-нче һәм 2-нче пунктларында күрсәтелгән затларга айлык гомерлек асрау күләме Рәсәй Федерациясендә судьяларның вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру (индексацияләү) өчен каралган күләмнәрдә һәм вакыт аралыкларында арта (индексацияләнә).

5. Әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсендәге 3-нче пунктында күрсәтелгән затларга айлык гомерлек асрау күләме Рәсәй Федерациясендә судьяларның вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру (индексацияләү) өчен каралган күләмнәрдә һәм вакыт аралыкларында, шулай ук судьяга айлык акчалата түләүнең теләсә нинди өлеше арткан (индексацияләнгән) очракта арта (индексацияләнә).

**Маддә 5. Әлеге Федераль канунның үз көченә керүе**

1. Әлеге Федераль канун рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Федераль канунда каралган түләүләр 2015 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә ашырыла.

3. 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы "Рәсәй Федерациясендә судьялар статусы турында" Рәсәй Федерациясе Кануны белән Рәсәй Федерациясендә отставкада булган судьялар өчен билгеләнгән социаль

гарантияләр әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсендәге 1-нче, 2-нче һәм 3-нче пунктларында күрсәтелгән затларга 2015 елның 1 гыйнварыннан башлап кагыла.

4. 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы "Рәсәй Федерациясендә судьялар статусы турында" Рәсәй Федерациясе Кануны белән отставкадагы судьяларга билгеләнгән таләпләр һәм чикләүләр әлеге Федераль канунның 2-нче маддәсендәге 1-нче, 2-нче һәм 3-нче пунктларында күрсәтелгән затларга 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап кагыла.

Россия Федерациясе

Президенты

В. ПУТИН

Мәскәү, Кремль

2015 елның 8 июне

N 139-ФЗ

"Аерым категория гражданнарына
социаль яклау гарантияләре турында"
Федераль канунга
кушымта

**2014 ЕЛНЫҢ 18 МАРТЫНА КАРАТА КЫРЫМ РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ СЕВАСТОПОЛЬ ШӘҺӘРЕ ТЕРРИТОРИЯЛӘРЕНДӘ ГАМӘЛДӘ БУЛГАН СУД СУДЬЯЛАРЫ**

**ВАЗЫЙФАЛАРЫН БАШКАРГАН СУДЬЯЛАР ВАЗЫЙФАЛАРЫНЫҢ РӘСӘЙ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУДЛАРЫ СУДЬАЛАРЫНЫҢ ВАЗЫЙФАЛАРЫНА ТУРЫ КИЛҮ ТАБЛИЦАСЫ**

| 2014 елның 18 мартына Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре территорияләрендә гамәлдә булган судларда вазыйфалар атамасы | Рәсәй Федерациясе судларында вазыйфаның исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Җирле (гомуми, административ) суд судьясы | Район суды судьясы |
| Җирле (гомуми, административ) суд рәисе урынбасары | Район суды рәисе урынбасары |
| Җирле (гомуми, административ) суд рәисе | Район суды рәисе |
| Апелляция суды судьясы | Республика югары суды, төбәк, өлкә суды, федераль әһәмияттәге шәһәр суды, автоном өлкә суды, автоном округ суды судьясы |
| Апелляция суды суд палатасы сәркатибе | Республика югары суды, төбәк, өлкә суды, федераль әһәмияттәге шәһәр суды, автоном өлкә, автоном округ судының суд коллегиясе рәисе |

| | |
|---|---|
| Апелляция суды рәисе урынбасары | Республика югары суды, төбәк, өлкә суды, федераль әһәмияттәге шәһәр суды, автоном өлкә суды, автоном округ суды рәисе урынбасары |
| Апелляция суды рәисе | Республика югары суды, төбәк, өлкә суды, федераль әһәмияттәге шәһәр суды, автоном өлкә, автоном округ суды рәисе |
| Җирле хуҗалык суды судьясы | Рәсәй Федерациясе субъекты арбитраж суды судьясы |
| Җирле хуҗалык суды рәисе урынбасары | Рәсәй Федерациясе субъекты арбитраж суды рәисе урынбасары |
| Җирле хуҗалык суды рәисе | Рәсәй Федерациясе субъекты арбитраж суды рәисе |
| Апелляцион хуҗалык суды судьясы | Арбитраж апелляция суды судьясы |
| Апелляция хуҗалык суды рәисе урынбасары | Арбитраж апелляция суды рәисе урынбасары |
| Апелляция хуҗалык суды рәисе | Арбитраж апелляция суды рәисе |
| Апелляция административ суды судьясы | Республика югары суды, төбәк, өлкә суды, федераль әһәмияттәге шәһәр суды, автоном өлкә, автоном округ суды судьясы |
| Апелляция административ суды суд палатасы сәркатибе | Республика югары суды, төбәк, өлкә суды, федераль әһәмияттәге шәһәр суды, автоном өлкә, автоном округ судының суд коллегиясе рәисе |

| | |
|---|---|
| Апелляция административ суды рәисе урынбасары | Республика югары суды, төбәк, өлкә суды, федераль әһәмияттәге шәһәр суды, автоном өлкә суды, автоном округ суды рәисе урынбасары |
| Апелляция административ суды рәисе | Республика югары суды, төбәк, өлкә суды, федераль әһәмияттәге шәһәр суды, автоном өлкә, автоном округ суды рәисе |